Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы 3-31 номерлы карары

**Казан шәһәре Думасының**
**2016 елның 14 декабрендәге 8-12 номерлы карарына карата**
**Татарстан Республикасы Прокуратурасы**
**протесты турында**

Казан шәһәре Думасының 2016 елның 14 декабрендәге 8-12 номерлы «Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары турында»гы карарына карата Татарстан Республикасы прокуроры урынбасарының 2024 елның 12 июлендәге 7-11-2024/5489 номерлы протестын карап тикшергәннән соң, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2016 елның 14 декабрендәге 8-12 номерлы «Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары турында»гы карарына карата Татарстан Республикасы прокуроры урынбасары протестын канәгатьләндерергә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетына (Р.Г.Гафаров) Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларына җирле әһәмияттәге объектлар өчен территориядән файдалану мөмкинлегенең (транспорттан файдалану мөмкинлегенең) максималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп күрсәткечләрен ачыклау өлешендә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлларга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**